**Республика Татарстан**
**Сармановский муниципальный район Рангазарское сельское поселение**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Рангазар**
**авыл җирлеге**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21 апреля 2022**

**КАРАР**
**№ 7**

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Рангазар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 маендагы 6 номерлы Рангазар авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә Рангазар авыл җирлеге советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Рангазар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 маендагы 6 номерлы Рангазар авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 2 пунктында «шулай ук» сүзләрен «, шулай ук федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү тәртибендә каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджет кредитлары бирү максатларында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасынын рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рангазар авыл җирлеге
Советы рәисе

А.Р. Шарипова